# Сарман




Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Сарман буйларында тирәктә;
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
Үрелеп чәчәк ата йөрәктә.

Сарман буйларыннан үткән чакта,
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын?
Күзләреңне тутырып карасыңмы,
Зәңәр таудан яулык болгармын?

Сарман буйларында яшел алан;
Печәннәре җитәр бер заман;
Кавышулары, иркәм, бик күңелле,
Әмма аерылышу бик яман.